Республика Татарстан
Совет Альметьевского
сельского поселения
Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге советы

**РЕШЕНИЕ**
2020 ел, 21 сентябрь

**КАРАР**
№ 8

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата түләү күләмен арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 06 августындагы 658 номерлы карары, Сарман муниципаль районы районы “Әлмәт авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 4 номерлы карары белән расланган Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкырга арттырырга.

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Интернет челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе Д.Ә.Газизов